**Татарстан Республикасы Зәй муниөипалҗ районы**

**Югары Шепкә авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**25.09.2017** **№ 72**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 һәм 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты нигезендә, Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирле референдум үткәрү инициативасы:

«2018 елда яшәү урыны Югары Шепкә авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәм югары Шепкә авыл җирлеге территориясендә сезонлы шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризамы, I төркем инвалидларыннан, көндезге форма буенча укучы, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар һәм студентлардан кала, алынган акчаларны җирле әһәмият мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару:

- Югары Шепкә авылы: зират коймалары кую; урамнарны яктырту (яктырткычларны ремонтлау һәм урнаштыру); балалар мәйданчыгын урнаштыру; чишмәләрне төзекләндерү, юлны өлешчә ремонтлау.

- Имәнлебаш авылы: балалар мәйданчыгы урнаштыру; иске агачларны кисү; урам яктырту (яктырткычларны ремонтлау һәм урнаштыру); зират коймасы кую.

- Иске Пәлчекәү авылы: янгын гидранты урнаштыру.

- Иске Пәлчекәү авылы: янгын гидранты урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Совет рәисе: А.Х.Ишматов